**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района Республики Татарстан**
**Совет города Арск**
**422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

# КАРАР

**« 25 » октябрь 2021 ел** **№ 7**

**Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Төбәк-Чокырча авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясын гамәлгә ашыру максатларында «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Төбәк-Чокырча авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 25 ноябрендә 13 сәг. 00 минутта Арча районы, Төбәк-Чокырча авылы, Ленин урамы, 17А йорты (кибет яны) адресы буенча билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Төбәк-Чокырча авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән һәм 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- зират коймаларын ремонтлау һәм буяу (буяулар сатып алу, эшләр өчен түләү);

- зират яны территориясен төзекләндерү;

- зират территориясендә инвентарь саклау өчен бинага материал сатып алу һәм төзү?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, җирлек башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. Арча муниципаль районы Төбәк-Чокырча авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Арча шәһәре башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны гражданнар күпләп җыела торган урында мәгълүмат стендында (Төбәк-Чокырча авылы, Ленин урамы, 17А йорты), интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы «Совет города Арск» И.Г.Нуриев